ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Транспорт салымы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Ике һәм аннан күбрәк транспорт чарасы теркәлгән әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән физик затлар өчен салым ташламасы салым түләүче физик затның салым ташламасы бирү турында гаризасы нигезендә транспорт чарасының берсенә карата бирелә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:
«$5^1$. Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче физик зат салым ташламасы бирү турында гариза тапшырмаган булса, салым ташламасы салым суммасы максималь исәпләнгән транспорт чарасына карата бирелә.»;

3) 6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасының транспорт салымы турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктының «г» пунктчасын

(Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 03 март
№ 5-ТРЗ